РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.01.2023 № 81-п

Күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә җир кишәрлекләрен һәм торак урыннарны муниципаль ихтыяҗлар өчен алу турында

Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең «Торак йортларны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле итеп тану турында» 2012 елның 30 декабрендәге 1938-п номерлы карары нигезендә, күпфатирлы йортларны авария хәлендә һәм җимерелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле дип тану турындагы карар нигезендә , милекчеләрнең күпфатирлы торак йортларны мөстәкыйль рәвештә җимерүне гамәлгә ашырудан баш тартуын, торак урыннар милекчеләренең Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 10, 12 пунктлары, Россия Федерациясе Җир кодексының 56.3 статьясындагы 2 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 10 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм торак урыннарны таләп белән каралган сроктан алданрак сатып алу юлы белән, ризалык бирүен исәпкә алып, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

**1.** Әлеге карар кушымтасы нигезендә муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен һәм аларда урнашкан торак урыннарын алырга.

**2.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының юридик бүлегенә:

**2.1.** әлеге карар кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә әлеге карарда күрсәтелгән җир кишәрлекләренең һәм торак урыннарының хокук ияләренә түбәндәгеләрне җибәрергә:

– әлеге карарның күчермәсен,

– Россия Федерациясе Җир кодексының 56.6 статьясындагы 10 пунктында каралган тәртиптә тапшыру турында хат белән күчемсез милекне алу турында хәбәрнамә,

– Россия Федерациясе Торак кодексының 32 статьясындагы 4 пунктында каралган муниципаль ихтыяҗлар өчен күчемсез милекне алу турында килешү проекты;

– алынырга тиешле объектларның кадастр паспортлары;

– РФ Торак кодексының 32 статьясы нигезендә каплау күләмен бәяләү турында хисап.

**2.2.** Әлеге карар кабул ителгән вакыттан алып 10 көн эчендә аның күчермәсен Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә җибәрергә.

**3.** Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәгълүматлаштыру бүлегенә:

– «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Саба муниципаль районының https://saby.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында алу турында карар урнаштыруны гамәлгә ашырырга;

– Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар https://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен билгеләнгән тәртиптә алу турында карарны бастырып чыгаруны тәэмин итәргә.

**4.** Саба муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына әлеге карарны үтәүгә юнәлдерелгән чараларны финанслауны тәэмин итәргә.

**5.** Әлеге карарның гамәлдә булу срогын өч ел дип билгеләргә.

**6.** Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Саба муниципаль районы
Башкарма комитеты Җитәкчесе М.Р. Ишниязов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башкарма
комитетының 2023 елның 26
гыйнварындагы 81-п номерлы
карарына кушымта

**Күпфатирлы торак йортны авария хәлендә һәм сүтелергә тиешле дип тануга бәйле рәвештә муниципаль ихтыяҗлар өчен алына торган җир кишәрлекләре һәм аларда урнашкан торак урыннары исемлеге**

| № т/б | Объект (җир кишәрлеге) адресы | Җир кишәрлегенең кадастр номеры, кв.м. | Җир участогы ның мәйданы, кв.м. | Күчемсез милек объекты (торак урын) адресы | Күчемсез милек объектының (торак урынның) кадастр номеры | Күчемсез милек объектының (торак бинаның) мәйданы, кв.м. | Күчемсез милек объекты ның төре | Күчемсез милек объекты (торак урын) исеме |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авыл җирлеге, Шәмәрдән авылы, Лермонтов тыкрыгы, 3А йорты, 1 нче фатир | 16:35:200107:129 | 512 | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авыл җирлеге, Шәмәрдән авылы, Лермонтов тыкрыгы, 3а йорты, 1 нче фатир | 16:35:200107:63 | 52,3 | Бина | Торак йортның бер өлеше |
| 2 | | | | Татарстан Республикасы, Саба районы, Шәмәрдән авылы, Азин урамы, 14 йорт,3 нче фатир | 16:35:080101:373 | 47.4 | Бүлмә | 3 нче фатир |
| 3 | Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Шәмәрдән авылы, Яңа Путь урамы, 6 йорт | 16:35:200103:49 | 1039 | Татарстан Республикасы, Саба районы, Шәмәрдән авылы, Яңа Путь урамы, 6 йорт, 1нче фатир | 16:35:200103:262 | 68.2 | Бүлмә | 1 нче фатир |
| | | | | Татарстан Республикасы, Саба районы, Шәмәрдән авылы, Яңа Путь урамы, 6 йорт, 3 нче фатир | 16:35:200103:261 | 51 | Бүлмә | 3 нче фатир |
| 4 | | | | Татарстан Республикасы, Саба муниципаль районы, Мөндеш тимер юл аерылышы бистәсе | 16:35:100501:25 | 36 | Бүлмә | 1 нче фатир |